Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советының утыз беренче утырышы

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

12 апрель, 2023 ел № 227

коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының рәсми сайты бүлекләрен урнаштыруга һәм тулыландыруга Бердәм таләпләр кертү турында

«Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимият оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карар кабул итте:**

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының 2019 елның 24 октябрендәге 220 номерлы карары белән расланган коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы рәсми сайтының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге бүлекләрен урнаштыруга һәм тутыруга Бердәм таләпләр, «Коррупциягә каршы көрәш» бүлегенең мәгълүмат белән тулыландыруга таләпләр» II өлешенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 2.2 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисә)» сүзләренә алмаштырырга (алга таба - Татарстан Республикасы Рәисе)»;

- 2.13 пунктының 2 абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Питрәч муниципаль районы башлыгы И.М. Кашапов